КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1293

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $3.4.2^3$ пункт өстәргә:

«3.4.2$^{3}$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү белгеч тарафыннан эшләнгән баланың дәресләргә йөрү буенча индивидуаль графигы нигезендә мәктәпкәчә яшьтәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә – 1 көнгә 5 сәгатькә кадәр, мәктәп яшендәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә – 1 көнгә 6 сәгатькә кадәр гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш)» таблицасының 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1.1. | Туклану белән тәэмин итү | Социаль хезмәт күрсәтелүчеләрнең тукลануын оештыру: | | |
| | | социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә; | ашау | көнгә 1 тапкыр социаль хезмәт күрсәтү чорында |
| | | мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә | ашау | социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 2 тапкыр (мәктәпкәчә яшьтәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр өчен), көнгә 1 тапкыр социаль хезмәт күрсәтү чорында (мәктәп яшендәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр өчен)». |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 90 көн узгач үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин